Удивительно, что эти письма доходили до адресата сравнительно быстро, около месяца. Например, письмо из Ленинграда вышло 24 октября 1941 года, а дошло до почты Дубъязского почтового отделения 18 ноября 1941 года.

*Стиль писем не изменён.*

ПИСЬМО ОТ АВГУСТА МЕСЯЦА 1941 ГОДА

*Здравствуйте, Нина и Валя, письмо ваше получила.*

*Осталась одна в маленькой комнате, все разъехались. Марусю с детьми проводили к матери в Бугульму, Паня с детьми тоже уехала. Она прислала открытку с вокзала, пишет, что всё ещё едут и не знают, куда их везут. Катю (Екатерина Михайловна – военный врач, дочь автора письма) взяли в армию, послала открытку с Московского вокзала, не знает, куда пошлют. 1 августа Алёша (Алексей Михайлович – сын автора письма, военный летчик) уехал в Сибирь, их школу перевозят на реку Иртыш. Все служащие в школе уезжают, увозят все свои вещи. 5 августа проводила весь Алёшин багаж, всё, что у него было, он приготовил сам. Очень ему было трудно одному свои вещи укладывать, и работа очень строго ему… Ехать с Алёшей не хочу, все едут в товарных составах, очень опасно. И Катины вещи, не знаю, что с ними делать. Народу едет много, с большими багажами. Хотела ехать к Поле, и решила остаться в маленькой комнате одна. Вася (сын автора письма, военный врач) уехал в Житомирскую область на практику, одно письмо было от него, поступил на работу, сейчас ничего не пишет. И о Коле (Николай Михайлович – сын автора письма, военный. Погиб в самом начале войны) ничего не знаю. Наверное, и он не знает, где я. Соседи отправили детей, остались М.Ж. мало бывают дома…*

*Нам сейчас всё дают по карточкам.*

*С приветом ваша мама и бабушка. Живите с богом, желаю вам всего хорошего, от г.б. доброго здоровья. Целую!*

ПИСЬМО ОТ 24 ОКТЯБРЯ 1941 ГОДА

*Здравствуйте Паня, Нина, Валя, Нина и Людмила. Получила ваше письмо. Спасибо.*

*Я по-старому живу одна. Вы все пишете и зовете к себе, но поехать нельзя, мы окружены. Живем неважно. Приходится переживать. Хлеба получаем 200 грамм, овощей нет. Но я сыта, а впереди*

*бог знает, что будет,  не знаю. Если будет возможность ехать, то я думаю поехать. Но не знаю, куда придется поехать. И Алёша зовет, и Поля; Лена пишет, что Вася живёт в городе Курган Челябинской области. Эльза с детьми в Казани, о Коле ничего не известно. Нина, узнай от Лены, где и как живет семья Коли на чужой стороне. Может быть плохо. Не забудь Колиных детей, они же наши. Катя пишет, что и думать о поездке нельзя. Сваха Алексеевна тоже собралась ехать и некуда не уехала. Посылает вам привет, скучает о своих внучатах. Ходили с ней на рынок. Купили Ниночке туфли. Заплатили 28 рублей. Собирались вместе ехать в Петропавловск. Её думаю оставить у Алексея. Мне хотелось ехать к Поле, она болеет, пухнут ноги. Очень огорчена, что я не приехала к ней. В Ленинграде опасно, и уехать нельзя. Может быть, это время пройдет, жизнь улучшится и мы увидимся. С приветом ваша мама и бабушка. Себя чувствую хорошо и вам желаю всего хорошего. От гб (господа бога) доброго здоровья. Живите с богом. 20 октября.*

ПИСЬМО ОТ 20 НОЯБРЯ 1941 ГОДА

*Здравствуйте, Паня, Ниночка и Людмилочка. Нина и Валечка, как живете.*

*Живу одна. Катя пишет, ехать никуда не велит. Алёша прислал справку, требует ехать к ним. Ехать опасно. Часто бывает тревоги, поезда не ходят. Алексеевна собиралась ехать, теперь уже поздно. Дорог нет. Если Алексей пошлет ей справку, то вместе с ней стали бы собираться. Но ехать мне не хочется. Постоянно тревоги. В дороге скорее можно помереть. Не знаем, что будет впереди. Вася писал, что работает военным врачом. Сейчас он в Курске. Там он будет недолго. Жизнь в Ленинграде неважна. Ехать с багажом не смогу. Оставишь Катины веши, Катя обидится. Ехать одна не смогу. Думаю, остаться на одном месте. Что будет н.в.б. Целую, ваша мама и бабушка. Желаю вам всего хорошего, от господа бога доброго здоровья.*

*Обратный адрес: город Ленинград, улица Красного Курсанта, дом 20А, квартира 3.*

Анна Дмитриевна не выжила в голодном Ленинграде. Умерла она 22 марта 1942 года. Ей было 67 лет. Похоронена на Пискаревском кладбище в братской могиле.

Было в семье всего 10 детей, трое умерли в младенчестве. Из семи детей:

1. Коля (1906 года рождения) в первые дни войны (4 июля 1941 года) погиб в Белоруссии.

2. Алёша (1908 года рождения) – военный лётчик. Подполковник технической службы. Место призыва: Татарская АССР. Награды: медали «За оборону Ленинграда», «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.», «За боевые заслуги», орден Красной Звезды, орден Красного Знамени.

3. Катя (1910 года рождения) – военный врач. Майор медицинской службы. Годы службы: 27.06.1941–18.06.1946. Боевые награды: орден Красной Звезды, медаль «За боевые заслуги».

4. Нина (1914 года рождения) – учительница. До, во время войны и после войны работала учительницей в Малоалатской начальной школе Дубъязского района ТАССР. Награждена медалью «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.», орденом Знак Почёта, медалью «За трудовую доблесть».

5. Вася (1917 года рождения) – военный врач. Подполковник медицинской службы. Годы службы: 1941–1946. Награды: медали «За оборону Сталинграда», «За взятие Кёнигсберга», «За победу над Японией»; «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.», орден Красной звезды.

5. Паня в начале войны эвакуировалась в Дубъязский район ТАССР, к сестре в деревню Малый Алат. Трудилась в тылу.

6. Поля осталась в Ленинграде.


114

Все графы заполнять полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество ДВОЕГЛАЗОВА Екатерина Михайловна
2. Звание Капитан м/с. 3. Должность, часть Начальник СКП-35

Представляется к К ордену " КРАСНАЯ ЗВЕЗДА".

4. Год рождения 1910 5. Национальность Русская 6. Партийность б.п.
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где, когда) Июнь 1941г.
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне не имеет
9. С какого времени в Красной Армии Июнь 1941г. 10. Каким РВК призван Ленинградским гор. Военкоматом
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) медалью " ЗА БОЕВЫЕ ЗАСЛУГИ".
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи [redacted]

Для подшивки

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

Капитан м/с. тов. ДВОЕГЛАЗОВА Е.М. служит в рядах Красной Армии с начала Отечественной войны, возглавляя весьма ответственный участок противоэпидемической службы, в качестве начальника Санитарно-контрольного пункта- 35. Свою работу проводит в основном на узловых и конечных станциях железных дорог фронта. В период наступательных операций 3-го Прибалтийского фронта Санитарно-контрольный пункт возглавляемый тов. Двоеглазовой сыграл большую роль в деле контроля за санитарным и эпидемиологическим состоянием движущихся во фронт пополнений. Благодаря бдительности и самоотверженной работы капитана м/с. тов. ДВОЕГЛАЗОВОЙ были своевременно выявлены и изолированы больные с инфекционными заболеваниями из эшелонов следуемых на фронт, и тем самым предотвращен занос инфекционных заболеваний в войска. Кроме этого тов. Двоеглазова принимала активное участие по оказанию медицинской помощи раненым при налетах вражеской авиации на ж.д. станции, где дислоцировался вверенный ей СКП. В работе проявляет много личной инициативы. Дисциплинирована и требовательна к подчиненным. Делу ЛЕНИНА-СТАЛИНА ПРЕДАНА. За прежнюю работу на Северо-Западном фронте награждена медалью " ЗА БОЕВЫЕ ЗАСЛУГИ". Капитан м/с. тов. ДВОЕГЛАЗОВА Е.М. достойна награждения" ОРДЕНОМ КРАСНАЯ ЗВЕЗДА".

НАЧАЛЬНИК 3 ОТД САНУПРА 3ПБФ
ПОДПОЛКОВНИК М/С.
/ РАСТОРГИН/.

Командир (начальник) (звание)

"7" Октября 1944 г.

*Наградной лист*



*Екатерина Михайловна Двоеглазова (справа) со своей старшей сестрой Полиной и племянницей Кларой*

Следующее письмо написано соседкой Анны Дмитриевны Двоеглазовой, уже после её смерти и адресовано дочери Екатерине Михайловне. Данное письмо просмотрено военной цензурой, об этом свидетельствует штамп военной цензуры.

## ПИСЬМО ИЗ БЛОКАДНОГО ЛЕНИНГРАДА А. МИХАЙЛОВОЙ

*Письмо датировано от 11 июня.*

*Милая Екатерина Михайловна! Постоянно думаю о Вас.*

*9 июня опечатали комнаты уехавших командиров. Опечатали и забили гвоздями и комнату Анны Дмитриевны, но списки вещей комиссия делать не стала, ссылаясь на то, что комната грязная и заразная. У других тоже вещи не описывали. Я просила дать ваш портфель с документами мне на хранение, но его искать не стали. Какие у вас вещи я, конечно, не знаю, но думаю, что всё будет цело, что там есть. Ваша мама говорила, что у вас есть меховая шуба и ковры. Я думаю,*

*что если они пересыпаны нафталином, то вещи не испортятся, так как комната солнечная, сырости нет. 3 июня был сильнейший обстрел нашего района. В нашем доме со стороны улицы выбиты все стёкла, со двора, к счастью, всё цело. Это мы такие счастливые, судьба нас пока хранит. Мы сделали ставни к своим окнам, на всякий случай. Я расстроена состоянием здоровья дочери. Она была на усиленном питании, и на грамм не прибавила в весе. Вид её жуткий, истощение подействовало на нервную систему. Сейчас она на бюллетене. Хотят её устроить в больницу при Академии, которая откроется. Но, есть препятствия. 1ое, что надо жить в том районе, и др. она нервничает и не спит, а с нею и я страдаю. Всё же у меня ещё теплится надежда, что с п.б. судьба нас пощадит, переживём это грозное время, война окончится, враг будет разбит и мы поживем спокойной хорошей жизнь. Хотелось бы познакомиться Вами. На днях пришло письмо из Ишима от жены вашего брата. Я писала и одна жена врача из нашего дома о смерти Вашей мамы. Они спрашивают, отчего она умерла и о вещах. Ответ они скоро получат, т.к. 7 июня соседка из нашей квартиры уехала в Ишим. Все им расскажет. Я лишилась с её отъездом хорошего честного человека, с которой мы жили душа в душу с 1924 года. Ей 40 лет, но мы были как подруги. Муж её подполковник в Тихвине. А сын только что окончил школу.*

*Одной из нашего дома, жене врача, отец послал командиром посылку: сухари, мед, сахар и шпик. Посылку не передали. Моей соседке, которые уехали в Ишим 2 раза не передали от мужа посылки. Вот что делается.*

*У меня много вещей, базаров нет, нет знакомств, то ни продать, ни поменять вещи не могу. Очень немногое удалось ликвидировать. Это меня тоже волнует. Уезжать не собираюсь: не могу все бросить (ведь мы рабы вещей), нет здоровья, ехать и не к кому.*

*Нервы плохо переносят обстрелы и тревоги, раньше геройски переносила и других подбадривала. Мы с Вашей мамой дежурили по дому очень часто с 8 до 12 часов ночи до декабря месяца, она, бывало, ляжет на парадном на скамейку и уснет. Все тревоги она сидела у нас в парадном на сундуке. И я рядом с ней. Была она очень бодрая. Очень живая, быстро бегала. Болела она всего 5-6 дней. Получили*

*Вы 2 моих письма: закрытое и открытое. Я послала вскоре после получения Вашего письма и отношение Управдому. Из ваш. Комната никаких мер очевидно не принимали, никто не приходил и никаких письменных требований к Управдому не поступало. Удалось ли Вам, Екатерина Михайловна, выяснить что-либо с посылкой.*

*14 дней я была на усиленном питании, кормили хорошо; но для нас было недостаточно, всё время хотелось есть. Это противное состояние, что всё время хочется есть. Хлеба 300 гр. – иждив., 400 – служащ. и 500 гр. – рабочим; дают крупу и сахару 400 гр. на месяц и мяса 400 гр. и всё нам мало. Я потеряла в весе 22 кг., дочь больше 30 кг.; больше 40% нормы. Сегодня холодный, пасмурный день, временами идет дождь. Дочь и её подруга поехали на дачу в Шувалово, где имеются грядки; у меня во дворе тоже грядки, нет сил поливать, полоть. Я не копала и не садила. Это оставила уехавшая соседка. Весь двор выкопан, все засеял госпиталь, который помещён напротив. Если бы вы смогли приехать, хоть на несколько дней, милая Екатерина Михайловна! Приехали бы прямо к нам. Пишите мне почаще, и я буду писать. Вы мне стали как родной, близкий человек. Желаю вам здоровья, бодрости и сил в вашем деле. Я очень люблю медицину и медицинских работников. Если бы была моложе, работала бы в госпитале, как в войну 14 года; я люблю ухаживать за больными и умею. Целую Вас крепко, А. Михайлова. Пишите чаше...*



*Ленинград, Пискарёвское кладбище*



*Обелиск павшим в боях Великой Отечественной войны сельчанам в селе Высокая Гора Высокогорского района РТ. 8 мая 2021 года*




*Памятник павшим сельчанам в деревне Малый Сулабаш Высокогорского района РТ*




*Обелиск погибшим землякам в селе Алан-Бексерь Высокогорского района РТ*




*Памятник павшим землякам в деревне Айбаш Высокогорского района РТ*



*Памятник павшим сельчанам в деревне Алаты Высокогорского района РТ*




*Памятник павшим сельчанам в деревне Ибря Высокогорского района РТ*




*Памятник павшим сельчанам на станции Куркачи Высокогорского района РТ*

# СЛОВО ПРАВНУКАМ ПОБЕДИТЕЛЕЙ

# ҖИҢҮЧЕЛӘР ОНЫКЧЫКЛАРЫНА СҮЗ БИРИК



Цена Победы была неимоверно велика. Война огненным смерчем прошла по просторам страны, принесла горе в каждый дом, в каждую семью. На полях сражений и в фронтовом тылу люди не щадили себя, отдавая без остатка все свои духовные и физические силы в борьбе с жестоким врагом.

Мы обязаны знать историю своих семей. Деды, прадеды отстояли честь и свободу, спасли меня и весь мир от ига фашизма. В этом всемирно-историческая заслуга и неоценимое величие боевых и трудовых свершений.

В преддверии Дня Победы в Великой Отечественной войне нужно каждой семье вспомнить своего героя. Бесценно, когда внуки и правнуки знают, где воевал их прадедушка, в каком звании и каких войсках. Просто замечательно, если в семье берегут фотографии, письма с фронта, ордена за боевые заслуги, как семейные реликвии.





# БАБАМ

*Истәлеккә бабаемнан калган*
*Иске сурәт, китап, медальләр.*
*Язлар җитсә, җанга килеп алар,*
*Үткәннәрен миңа сөйләрләр:*
*Аяз күкне кара болыт каплап,*
*Сугыш дигән афәт килгәнне,*
*Егермедән чак-чак үткән егет,*
*Камуфляжлы кием кигәнне,*
*Сөйләр алар, ничек: «Яшим!» – диеп,*
*Үлем белән янәшә баруын.*
*Ахыргача яу кырында булып,*
*Исән-имин кире кайтуын.*
*Ачлык аша, сугыш аша үткән,*
*Батыр егет ниләр кичергән?..*
*Кочагына кысып салкын мылтык,*
*Киев... Моздок... Терек кичелгән.*
*...Иске сурәт, китап, медальләр*
*Күтеп ала ел да май аен.*
*Мылтык кысып кочагына бабай*
*Үлмәс полкта кайта ел саен.*

*Ильяс Хәкимҗанов,*
*Суыксу мәктәбенең*
*4 нче сыйныф укучысы*





*Әдһәм Әһли улы Гайнуллин*

# СУГЫШ АФӘТЕ КАБАТЛАНМАСЫН

*Минем бабаем – Әдһәм Әһли улы Гайнуллин – 1944 елның 15 гыйнварында Әтнә районы Бәрәскә авылында туа. Минем бабам сугыш вакытлары турында искә алып, шулай сөйли иде:*

*«Сугыш елларында бик кечкенә сабый булганмын. Бала вакытымда дөньяның бик күп илләрендә яшәүче төрле милләт халыкларының зур фаҗига кичергәннәрен аңлап та бетермәгәнмен. Бу сугыш елларында, аннан соңгы елларда да, бүгенге көннәрдә дә аның кайтавазы ишетелеп тора сыман. Аерым кешеләргә генә түгел, барлык йортларга да сугыш кайгысы, газабы, ачлыгы кермичә калмаган. Һәрбер йорт саен әтисе, абыйсы, якын туганы йә үлеп калган, йә гарип кайткан.*

*Үземә Германия Демократик Республикасының Берсени шәһәрендә солдат хезмәтен үтәргә насыйп булды. Менә шунда мин сугышның нәрсә икәнен аңладым. Безне, бер төркем солдатны, сугышчан әзерлек отличниклары дип, фашистларның Заксенхаузен концлагерена экскурсиягә алып бардылар. Монда күргәннәрне сөйләп-язып аңлатырлык түгел. Сабый балалардан алып олы яшьтәге төрле илләрдән куып китерелгән халыкны мичләрдә яндырганнар, атканнар, асканнар. Лагерьдагы баракларны, экспонатларны күреп, мин анда ник килгәнемә үкенеп, авырып кайттым.*

*Берлин шәһәрен урталай бүлеп, Шпрее елгасы буйлап стена корганда, безнең часть танклары Америка танклары белән пушкаларны терәшеп, экипажлар танкларыннан чыкмый, тәүлекләр буе тордылар. Берлин стенасын инде җимерделәр. Хәзер болар берсе дә хәрби сер түгел.*

*Минем әтием сугыштан, бер аягын өздереп, гарип булып кайт-*

*ты. Шул сугыш яралары аны 42 яшендә мәңгелеккә алып китте. Без 3 бала әни итәгенә ябышып калдык. Сугыш еллары гына түгел, сугыштан соңгы 1946, 1947, 1948 еллар халык өчен авыр ачлык еллары булды. Күмәк хуҗалыкның алган икмәген план-заданиегә озаттырып бетерәләр иде. Хезмәт көненә стаканлап кына бирделәр. Мин бала вакытымда ипине туйганчы ашаганымны белмим. Мин генә түгел, авылыбыз белән. Ничек итсәләр иттеләр, балаларын үстерергә тырыштылар: көндез фермада эшләп, төнлә чыпта суктылар. Тәүлегенә 3 сәгать йокладымы икән әни? Төнлә чыпта сугарга лампага май-керосин кирәк. Ә ул кибеткә кыш буена 1-2 мичкә генә кайта. Бүген Арчага керосинга барырга ат бирелгән дигән хәбәрне ишетүгә, без, малайлар, кем иртүк сәгать 3-4 тә тора ала, керосинга чиратка менеп басабыз. Әле ат Арчага китәсе, китмәгән әле. Керосин чираты җитә, чирек шешәне кочаклап туңып беткән инде, туңу безгә берни түгел. Шулвакыт яңа хәбәр: сезгә керосин юк, сезнең пай взносыгыз түләнмәгән. Шул пай взносы түләнмәгәч, керосин бирелми икән, юк икән. Керосин мае чыпта сугу өчен генә түгел, әле безгә дәрес тә хәзерләргә кирәк. Җитмәсә, минем китапханәдән дә китаплар алып укыйсым килә. Юк шул, кич белән укып булмый, әни майны бетерәсең дип сүгә. Сугыш чоры балалары дигәннән, мин үзем, Гайнуллин Әдһәм, 1944 елның гыйнвар аенда туганмын һәм 1944 елның июль ахырында мин кабыклы арбада әнигә «арыш уруда булышырга» басуга чыктым. Минем хезмәт кенәгәсе «дөрес тутырылмаган». 1947 елгы уракта мин инде чын малай булып, энемне шул ук кабыклы арбада көлтә чүмәләсе төбендә карап утырам. Арбаны гел күләгәле якка күчерәм.*

*Безнең балачагыбыз барыбер үзенә күрә күңелле иде. Ашыйсы килә димәдек, киярргә юк димәдек, булмаса да, аяк туңа дип тормадык, яланаяк йөгердек. Мәктәптә укыдык. Мин өйдәгеләрнең: «Дәресләреңне хәзерләдеңме?» – дип сораганнарын белмим. Аларның мәшәкатьләре бездән башка да баштан ашкан иде.*

*Сугыш чоры балалары дигәннән, бик күп яшүсмерләрне сугыштан соң, елатып, ФЗӨ, һөнәр мәктәпләренә алып киттеләр. Бичараларның бик күпләре туган илләренә кайта алмыйча калдылар. Бик күп кызлар урман кисүдән, торф чыгарудан, фермада бушка эшләүдән туеп, кемнең кем булуына карамый, читкә алып китәм дисә, шуңа*




*Сагида Ахметзянова, ученица Высокогорской средней школы №1. 12 лет*

*кияүгә чыгып китте. Чөнки ул вакытта авыл кешесенә паспорт бирелми иде.*

*1942 елгы кырыклап сугыш чоры баласыннан авылда мин белгән 3-4 кеше генә бар хәзер. Исән вакытларында, һичьюгы, аз булса да, аерым рәвештә пенсияләренә өстәмәләр булыр иде, хәер, алар тәрбия күргән буын түгел инде, күп гомерләре дә калмагандыр.*

*Хәзерге вакытта тормышыбыздан канәгать, бәхетле картлык кичерәбез. Башка сугыш афәте кабатланмасын иде».*

*Эх, бу рәхимсез сугыш! Күпме балаларны ятим иткән, балачагын урлаган. Алар авырлыклар алдында сынмаганнар, сыгылмаганнар. Туган ил өчен бердәм булып, көнне төнгә ялгап, барлык авырлыкларны җиңгәннәр, тормыш юлында югалып калмаганнар, дөрес юлны тапканнар. Бабаем да, армиядән кайткач, әбиемә өйләнеп гаилә корган. Алар Рөстәм һәм Рәис исемле ике ул үстергәннәр. Бабаем башта трактор бригадиры, аннан хисапчы, ә соңгы елларда 67 яшенә кадәр ревком председателе булып эшләде. Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда,*

*аңа 73 яшь. Ул әби белән бәхетле гомер кичерә. Туган җирен бик ярата һәм хөрмәт итә. Кечкенәдән авырлыклар, михнәтләр күреп үссә дә, бүгенге тормышка ул шөкер итә. Аның һәрбер көне Аллаһы Тәгаләбезгә рәхмәт әйтеп, намаз укудан башлана. Инде олы яшьтә булса да, бер минут та тик утыра белми, абзар тулы мал асрый, бакчачылык белән шөгыльләнә, оныкларын тәрбияләргә булыша. Артык тынгысыз инде ул, чөнки авыр еллар шулай тәрбияләгән һәм чыныктырган.*

*Илебездә тынычлык, өстәлләрдә муллык. Гаиләләргә сугыш китергән кайгы-хәсрәтләр, хатирәләр булып кына калсын иде. Бу бәла – казалар булмасын өчен, безгә, яшь буынга алар турында онытмаска, тарихтан сабак алырга кирәк. Яшьлекләрен сугыш урласа да, картлыклары бәхетле булсын сугыш чоры балаларының! Алар бу бәхеткә бик лаек.*

*Зөһрә Гайнуллина,*
*Биектау 3 нче урта гомуми белем мәктәбенең*
*7 нче сыйныф укучысы*



*Егор Гагулин, ученик Шапшинской средней школы. 8 лет*



*Наилә Бари кызы*
*Сабитова (Бариева)*

# ӘТИСЕЗ ҮТТЕ БАЛАЧАГЫМ

*1941 елның августында, әти фронтка киткәндә, миңа 6 яшь була. Шуңа әтине хәтерләмим дә.*

*1941 елның 4 августында энем Якуб туды. Мине сөенче алырга йөгерттеләр. Әти – бригадир, наряд биреп кайтып килә. Мин: «Әти, малай бар!» – дип кычкыргач, ул куанычыннан мине күккә күтәреп чөйде. Шул бераз истә. Аннан авылның Дөбъязга чыккан юлыннан сугышка озата барганыбыз хәтердә. Энем туу шатлыгының чиге юк иде, чөнки моңа хәтле туган малай үлгән булган. Әмма озак бәйрәм итәргә мөмкинлек булмады.*

*Ирләр берәм-берәм сугышка китә торды. Әтигә дә повестка килде. 14 август көнне озаттык. Эшелон җыелып җитмәү сәбәпле, әти бер көн Казанда туганнарында кунды.*

*Сентябрьдә мин укырга кердем. Әти, минем укырга барасын белеп, сандыкка күп итеп дәфтәрләр, буяулар алып калдырган. Мин – сабый, мәктәптә мактандым. Күпләрнең дәфтәре юк иде – шуларга көн саен дәфтәр ташыдым.*

*Көннәрдән бер көнне әтинең беренче һәм соңгы хаты килде. Ул анда: «Ут сызыгына килеп җиттек», – дип язган иде. Мәгънәсен еллар үткәч кенә аңладым. Әни бу хатны кадерле документлар саклана торган урынга куйды. Көннәр үтә торды, 1942 елның бер көнендә хат*

*ташучының капка төбендә аптырап торганын күреп алдык. Ул әтинең хәбәрсез югалуы турындагы хәбәрне китергән икән. Әби-бабай бик еладылар, шулай да әнигә сабырлык теләделәр, чөнки әти фин сугышында булып, исән-сау әйләнеп кайткан иде. Өметләнергә куштылар.*

*Мин 5 класска җиттем. Немец теле укый башлагач, яңалиф хәрефләре белән охшашлыкларын күреп, әтидән килгән теге хатны укырга булдым. Бик еш укыла торгач, шәмәхә карандаш белән язылган хатның хәрефләре танылмый башлады. Шулай итеп ул юкка да чыкты...*

*Әтисез гомер үтә торды. Без: бабай, әби, мин, сеңлем, Якуб энем – әни тәрбиясендә калдык. Әни бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эштә булды. Бабаем да бик хезмәт сөючән кеше иде. Ничек тә әнигә булышырга теләде. Мин, олы бала булгач, бабайның уң кулы булдым. Сыерга печән әзерләү, кышка утын хәстәрен күрү, йорттагы бакчаны казу, бәрәңге утырту, аны утау кебек эшләрне без башкара идек.*

*Кышлар бик салкын булды. Агачлар өшеде. Хезмәт кулы җитмәгәнлектән алынып бетмәгән бәрәңге безгә азык булды. Сеңлем Һиндия белән икәү шул черек бәрәңге – күкәринне җыеп, җәен тукланыр өчен киптереп куя идек. Ашарга яраклы үсемлекләр җыеп, аш әзерләдек. Күкәринне төйгәч барлыкка килгән он белән ашны куертып җибәрә идек.*

*Мәктәп балалары белән бергә, үзебез хәтле чиләк күтәреп, башак җыйдык. Чабатадан, карлы-бозлы сулар ерып, колхоз басуында бәрәңге алдык. Кышын, флаглар җилфердәтеп, басуга тирес түктек, кар тоттык, көл җыйдык.*

*Икенче-өченче класста укыган вакытта тиф белән авырдым. Чыршы бәйрәменә төшә алмадым. Күрше Рәхилә апа Яңа ел бүләге һәм бер ботак чыршы алып керде. Ә икенче күршебез Фатыйма апа ясләдә эшли иде, ул тозлы балык башы җибәргән. Шуны саңакларына хәтле ашаганмын. Бу авырудан соң беренче ашаган ризык булган.*

*Малай кеше булмасам да, бабай артыннан арба өстерәп, кайтып кермәдем. Бабам умартачы иде, аңа төтен өрдерергә булыша идем. Җәй ахырында, бал суыртканда, аерырга ярдәм иттем. Бик арыта иде, шулай да баллы булу тормыш өчен куаныч иде. Аны сатып, кыш өчен он алып калу җаен эзләдек. Онның поты – 1800 сум. Балны сатарга сишәмбе көн бабай белән Мәмдәл базарына төшә идек. Иртәдән тө-*

*шеп, базарда озак торгач, ашыйсы килә. Бабай сатучылардан бәрәңге пәрәмәче, кабартма алып килеп сыйлый иде.*

*1945 ел җитте. Сугыш бетү хәбәрен мәктәптә линейка җыеп әйттеләр. Ул көнне дәресләрне кыскарттылар, шатлыклы хәбәрне әйтергә өйгә кайтарып җибәрделәр. Ишектән керү белән: «Сугыш беткән, әби, этиләр кайтачак!» – дип кычкырдым. Әби бик авырый иде. «Мин ул көннәрне күрмәм инде», – диде. Чыннан да, 14 май көнне үлеп китте.*

*Исән солдатлар берәм-берәм кайта башладылар. Авыл көн саен кемнедер көтте. Балалар әтиләрен кочаклап ала... Кеше әтисен кочаклап булмый шул, моңаеп, өйгә кайтып китә идек. Шулай итеп, 30 яшендә әтиебез Әхмәтҗанов Бари Әхмәтҗан улы хәбәрсез югалды. Әтисез үтте балачагым...*

*Авыр еллар булса да, бик укыйсым килде. Җиде классны бетергәч, күрше Мәмдәл авылына сигезенче класска укырга бардым. 1952 елда, 10 классны тәмамлап, Казан педагогик институтына укырга кердем.*

*1953 елның мартында яраткан бабам да үлде.*

*1956 елда Пенза өлкәсенең Бестянка авылына укытырга җибәрделәр. 3 ел эшләгәч, үзем укыган туган авылым Чувашиле мәктәбенә кайтып, 40 елга якын балалар укыттым. Хезмәтемне яратып башкардым.*

*Әти киткәндә 10 көнлек булып калган энем Якуб, бер тапкыр да «әти» дип әйтә алмыйча, инде үзе дә бакыйлыкка күчте. Улы армия хезмәтендә фаҗигале һәлак булгач, хәсрәтне кичерә алмады. Сеңлем Һиндия дә бу дөньяда юк инде. Әнием Фатыйма, озын гомер кичереп, гомере буе әтине сагынып, 89 яшендә үлеп китте.*

*Авырлыкларны күп күрдек. Ул вакытта ил белән бергә күрдек.*

*Сәвия Мәгсум кызы Галиева,*
*Чувашиле авылы китапханәчесе.*

# Я ГОРЖУСЬ СВОИМИ ДЕДАМИ

## *БЕССМЕРТНЫЙ ПОЛК В ИСТОРИИ СЕМЬИ ФЕОКТИСТОВЫХ*



*На фото прапрадед – справа с деверем Павловым*

*Фамилия «Феоктистов» в переводе с греческого означает «Богом созданный».*

*На войне погиб мой прапрадед со стороны папы, Феоктистов Василий Максимович, 1907 года рождения. В 1927 году прапрадед скрепил свою жизнь узами брака с Павловой Екатериной Александровной, 1908 года рождения. В семье родилось шестеро детей: 3 сына и 3 дочери. Вся семья благополучно жила в селе Мамонино Дубъязского района (ныне Высокогорского). До войны семья занималась земледелием, в 30-ые годы активно участвовала в организации колхоза.*

*Прапрадед мобилизован на фронт Дубъязским РВК, красноармеец, 1181 сп., 356 сд., 61А, в возрасте 34 лет.*

*Простившись с детьми и женой, прадед ушёл на фронт. В это время младшему ребёнку был один год. В феврале 1942 года у прадеда родился ещё один сын (шестой ребёнок), о котором он никогда не узнает…*

*В.М. Феоктистов был рядовым 1181 стрелкового полка. Боевой путь, к сожалению, не известен.*

*Судя по документам, прапрадед захоронен в братской могиле, в селе Кривцово Болховского района Орловской области. Погиб он*

*22 февраля 1943 года. Немцы заняли село Кривцово летом 1942 года, а освобождено оно было только в феврале 1943-го. Информацию о захоронении в 1988 году сообщили моему прадеду Феоктистову Ивану Васильевичу студенты Казанского университета, бойцы «Снежного десанта».*

*Воинам, погибшим в боях при освобождении села Кривцово, установлен памятник. Памятник с изображением танкиста и красноармейца на фоне мемориальных плит. Памятник изготовлен из бетона, установлен на одноступенчатом стилобате. Имеется централизованный подвод газа. Вечный огонь зажигается в дни памятных дат. Ширина памятника – 4 м, длина – 5 м, высота – 4,5 м. Количество захороненных составляет 1201 человек.*

*Василий Максимович не вернулся с фронта. 7 июня 1945 года умерла и его жена, от голода, отдав последний кусок хлеба своим детям. Таким образом, она спасла жизнь своих детей. Эти дети остались «голыми» сиротами. Самого младшего, трёхгодовалого Григория, усыновила односельчанка Тихонова Аксинья. Мой прадед Иван Васильевич и его сёстры и братья работали с детских лет, чтобы выжить. Чтобы погибший отец мог ими гордиться.*

*Путь Василия Феоктистова на войне был короток, но он отважно боролся за счастливое будущее своих детей. Дома семья верила в отца и в страну. Я даю себе слово посетить братскую могилу прапрадеда, возложить цветы. Мне важно сказать «спасибо». Пусть мой прапрадед знает, я им горжусь.*



ИЗВЕЩЕНИЕ

Ваш мл. сержант
(муж, сын, брат, воинское звание)

24 февраля 3 Феоктистов Василий Максимович
(фамилия, имя и отчество)

уроженец Тат. АССР Дубъязовский р-н с. Мамонкино
(область, район, деревня и село)

в бою за Социалистическую Родину, верный воинской присяге, проявив геройство и мужество, был убит 22 февраля 1943 года

(убит, ранен и умер от ран)

похоронен д. Нижние Ростоки Арсеньевского р-на Тульской об.
(место похорон)

Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии (приказ НКО СССР № 220, 1941 г.)

М. П.

Командир части

Комиссар части



Н. К. О.

Войсковая часть

ИЗВЕЩЕНИЕ

Ваш мл. сержант командир отделения

Протасов Александр Тихонович

уроженец Тат. АССР Дубъязовский р-н село Мамонкино
(область, район, деревня и село)

в бою за Социалистическую Родину, верный воинской присяге, проявив геройство и мужество, был убит в бою 22.9.43 г. за д. Волоти Починковского р-на Смоленской области
(убит, ранен и умер от ран)

похоронен в братской могиле с. Волоти Починковского р-на Смоленской обл.
(место похорон)

Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии (приказ НКО СССР № )

М. П.

Командир части

(Городской или районный военный комиссар)

## БЕССМЕРТНЫЙ ПОЛК В ИСТОРИИ СЕМЬИ ПРОТАСОВЫХ

*Фамилия «Протасов» в переводе с греческого означает «стоящий в первом ряду».*

*Семья прапрадеда Протасова Александра Тихоновича, 1904 год рождения, с Андрияновой Лидией Васильевной, 1908 года рождения, образовалась в 1927 году. Семья жила в селе Мамонино. В счастливом союзе родилось пятеро детей: 4 мальчика и 1 девочка – моя прабабушка Прасковья. Прапрадедушка Александр был очень строгим, важным и честным человеком. Очень любил свою единственную дочь, так, например, когда Прасковья пошла в школу, отец смастерил ей школьный чемодан.*

*В 1941 году он был мобилизован на фронт Дубъязским РВК, красноармеец, 332 сд., в возрасте 37 лет. В три часа ночи прапрадед простился с детьми и женой и пошел в пункт сбора, дочери наказал смотреть за братьями и помогать матери.*

*Служба прапрадеда прошла в 332 Ивановской стрелковой дивизии имени М.В. Фрунзе в звании сержанта, командира отделения. В семье бережно хранится платочек от отца с фронта с надписью «любимой доченьке» от тяти (тятя – старинное название отца).*

*Боевой путь прапрадеда Александра начался в городе Казани, а дошёл он до Эстонии. 17 января 1943 года за подвиг прапрадед был награждён медалью «За боевые заслуги». (Номер записи: 18560505. Подвиг: наградить Александра Тихоновича за то, что он 17.01.43 года при штурме гор. Веань (?) точной наводкой своего миномёта разрушил 2 ДОТа и уничтожил при этом 2 станковых пулемёта противника с их прислугой, из которых противник вёл губительный огонь по наступающим нашим бойцам. Тов. Протасов за время боя с немецкими оккупантами трижды ранен).*

*Во время боя за Социалистическую Родину – за деревню Волоты Понизовского района Смоленской области был убит 29 сентября 1943 года. Похоронен в братской могиле Понизовского района, д. Волоты.*

*Таким образом, изучив различные документы из нашего семейного архива, побеседовав с бабушкой Культяповой Елизаветой Ивановной, я узнал очень много о членах нашей семьи в годы Великой Отечественной войны. Двое моих прапрадедов сражались в Великой Отечественной войне. Прапрадед Александр награждён медалью «За боевые заслуги». Оба они погибли во время боевых действий, защищая Родину.*

*Мои предки достойно сражались на фронтах Великой Отечественной войны, трудились в тылу, помогая фронту. Они внесли большой вклад в дело Победы. Я горжусь своими предками. В День Победы мы с гордостью несём портреты моих прапрадедов в Бессмертном полку!*

*Я обещаю побывать на могилах моих прапрадедов, передавать историю своего рода своим детям и внукам.*

*Я горжусь своими дедами!*

*Артём Культяпов, ученик 9 класса*
*Березкинской основной школы*
*Высокогорского района РТ*



*Акция «Бессмертный полк» деревни Березка. 2019 год*

# КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ ТЫНЫЧЛЫК, БӘХЕТ ӨЧЕН КӨРӘШСЕН ИДЕ!

*Халкыбызның күп гасырлык тарихында героик һәм шул ук вакытта фаҗигале, кайгы-хәсрәт белән сугарылган сәхифәләре бик күп. Шундыйлардан берсе – Бөек Ватан сугышы. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә. Япь-яшь егетләр, кызлар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка китәләр. Тылда калганнар да Җиңү өчен дип, бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә. Ватан өчен яу кырларында мәңгегә ятып калучылар арасында 300 дән артык авылдашыбыз да бар. Нинди зур югалтулар! Безнең буынны саклап калган кешеләрнең батырлыгы беркайчан да онытылмас! Безнең бәхетле тормышыбыз һәм азатлыгыбыз өчен түгелгән канны ничек онытырга мөмкин соң?! Без, укучылар, артта калган шушы вәхшәтле көннәрнең эчтәлеген ныграк аңлау өчен Бөек Ватан сугышында җанын-тәнен биреп фашист илбасарлары белән көрәшкән сугышчылардан, ә хәзерге вакытта ветераннар булып саналган бабаларыбыздан сорашып беләбез. Сугышның ачы хәсрәтләре аларга бик күп кайгы алып килгән һәм алар бу көннәрне искә алганда күз яшьләрсез сөйли алмыйлар. Авылыбызда сугыш ветераннары калмады, тыл ветераннарының саны да елдан-ел кими бара. Шуларны истә тотып, без алар белән элемтәдә торабыз, ярдәм итәбез.*

*Еллар үтә, һәр ел тарихта үзенең эзен калдыра. Еллар көннәрдән тора, ә һәр көн таң белән башлана. Менә шундый таңнарның берсе – 1941 елның 22 июнь таңы. Якшәмбе көн. Кояш чыгарга иртәрәк әле. Кешеләр тыныч йокыда. Бөтен табигать сихри тынлыкка чумган. Кайдадыр еракта чут-чут итеп сандугач сайравы гына ишетелә. Шушы тынлыкны бозып, кинәт көнбатыштан самолётлар гөрелтесе ишетелә. Шомлы үкерү тавышы көчәйгәннән-көчәя бара, кешеләр ни булганын аңлап бетергәнче йөзләгән, меңләгән хәрби самолётлар тыныч шәһәрләр һәм авыллар өстенә бомбалар яудыра башлый. Күпкатлы йортлар гөрселдәп авалар, күккә тузан болыты күтәрелә, коточкыч янгын башлана. Дөньяның асты өскә килгәндәй була. Урамнарда, юлда очраган бөтен нәрсәне вата-сыта килүче свасти-*

*калы танклар, бала-чаганың, аналарның ачынып елаган тавышлары, кан, үлем...*

*Тиздән радио туган илебезгә фашистлар Германиясенең хыянәтчел һөҗүме турында куркыныч хәбәр тарата. Бөек Ватан сугышы менә шулай башлана. Һәркем өчен дә авыр сынау еллары башланып китә. Авылдашларыбыз да бу көнне мәңге онытмас.*

*Исхакова Наилә Хәсән кызы истәлекләреннән: «Җәйге матур көн. Йокыдан уяндым. Германия сугыш башлаган дип, кешеләр шау-гөр килә. Чөнки авыл советы безгә каршы гына иде. Хәзер иртәгесен яшьләрне армиягә ала башладылар. Авыл советына җыелып, гармуннар белән атларга утырып җырлап, кайсы елап китәләр. Ә балалар авыл башына кадәр аларга ияреп барабыз. Картлар азан әйтеп озаталар».*

*Ир-егетләр, абыйлар изге Ватан өчен сугышка китә. Авыл башына чыгып, хатыннар – ирләрен, сабыйлар әтиләрен, яшь кызлар сөйгәннәрен фронтка озата. Алар сугышның нинди куркыныч икәнлеген белми шул әле. Тиздән, бик тиздән балалар үзләренең ятим каласын да, балачаклары буразна арасында үтәселәрен дә аңламый. Сугыш рәхимсез. «Әткәй, китмә!» – диеп елаган балаларны ишетми ул сугыш. Тылда калучыларга да җиңел булмый. Ләкин солдат әтиләрен, кардәш-туганнарын бөтен нәрсә белән тәэмин итеп тору өчен, станоклар артында торучылар да, колхоз басуларында алны-ялны белмичә эшләүчеләр дә хатын-кыз, карт-корылар, бала-чагалар була. Әйе, авылда шулар гына кала. Тормышны алып барырга кирәк: кырда игенен дә игәргә, ач-ялангач та булмаска, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләргә, гомер буе бетмәс кебек тоелган налогын да илтеп түләргә. Әтиләре, абыйлары сугыш кырында батырларча көрәшкәндә, тылда әниләр, сабый балалар үзләрен аямыйча эшлиләр. Сыкранмый, сызланмый һәммәсен дә үз җилкәләрендә күтәрәләр алар.*

*Ә Фатыйма Шакир кызы Сафина сугыш башланган вакытны болай искә ала: «Безнең яшьлегебез авыр сугыш елларына туры килде. Сугыш шау-шуын ишетмәсәк тә ачлык-ялангачлык, авыр хезмәт үзәккә үтте. Авылда ир-атлар сугышка киткәнлектән, көчебез җитмәгән бик авыр эшләр башкарырга туры килде. Сугыш башлануга ир-атлар сугышка китә башлагач, МТС та бер айлык трактористлар курсы ачтылар. Мине шунда укырга җибәрделәр. Ул вакытта бармыйм, эшләп булмас дип тору юк».*



ЭДУАРД
НУРГАЛИ УЛЫ
НУРГАЛИЕВ

*Сугыш, сугыш... Кемнәрнең язмышына кагылмаган да, кемнәрнең башларына кайгы, күз яше, хәсрәт китермәгән ул. Сугыш чоры балалары ачлыкны да, ялангачлыкны кичергәннәр. Балачак ул кеше гомерендә бер генә була. Шуңа күрә аның һәр мизгеле кадерле, алар бервакыт та да онытылмый.*

*«Мин 1940 елның 12 сентябрендә Казаклар авылында туганмын. Миңа 11 ай булганда, сугыш башланган һәм әтине сугышка алганнар. Бу 1941 ел була. Шул ук елның 20 декабрендә «үлгән» дигән хәбәр килә. Мин әтине белмим, «әти» дип әйтә дә алмадым.*

*Сугыш вакытында бөтен авырлык әниләргә булды. Мәчет бинасында балалар бакчасы иде. Мин кәҗә сөте салынган шешә күтәреп шунда барганымны хәтерлим. Әни белән басудан черек бәрәңге җыя идек. Ачлык, ялангачлык. Әтиле балалар икенче тормыш белән яшәде. Әмма ярты авыл әтисез иде», – дип искә ала Эдуард Нургали улы Нургалиев.*



*ЗАКИРОВА*
*НУРДИДӘ*
*ГАЗИЗ КЫЗЫ*

*«Әти» сүзен әйтергә тилмерүчеләр күп булган ул чорларда. Шундыйларның берсе 1939 елның мартында Казаклар авылында туган Закирова Нурдидә Газиз кызы. Аның балачак еллары авыр сугыш белән бәйле: «Мин әтине хәтерләмим дә. Әнинең сөйләвеннән генә беләм. Әти Тәтештә агрономнар әзерләү курсында укыган. 1941 елның 22 июнендә сугыш башлангач, 6 айга уенга дип чакырылган әти, сугышка киткән. Соңгы хатын Чкалов шәһәрендә госпитальдә яткан чакта язган. Шуннан хәбәрсез югалуы турындагы кәгазь килгән. Әтидән мин яшь ярымлык булып калганмын». Нурдидә апа, бүген дә бу истәлекләрне тыныч кына искә ала алмый. Күзләрендә яшь тамчылары, тамагына төер тыгыла: «Мин әбием Нәфисә тәрбиясендә үскәнмен, чөнки әни эштән кайтып кермәгән: окоплар казыган, колхозда төрле эшләр башкарган. Кул арасына керә башлагач, мин дә әнигә булыша идем. Печәнен дә чаптык, арба белән утын да ташыдык, бәрәңге дә алыштык. Әни әтиле балалардан ким итмәде. Актык сарыгын сатып булса да киендерде. Ач-ялангач итәргә теләмәде».*

*Бөтен эш алар җилкәсенә төшә. Тылда ачлы-туклы килеш барсын да эшләргә туры килә. Ил өчен, фронт өчен дип, көнне төнгә ялгап эшлиләр. Колхоз терлекләрен карарга, урак урырга, ындыр табагында эшләргә туры килә. Ләкин зарланмаганнар, иңнәренә төшкән авыр йөкне җигелеп тарткан алар. Әбиләребез, сугышка киткән ир-егетләребезне алмаштырып, трактор, комбайн штурвалы артына утырган. Җир сөрергә дә, тырмаларга да, чәчәргә дә туры килгән аларга.*

*Әле ничектер мәктәптә укыйсы да бар. Сугыштан соң уку еллары*

*турында Нурдидә Газиз кызы Закирова искә ала: «Сугыш арты елларында мәктәптә укучылар саны артты, 25әр балага җитте. 1947–1954 елларда Казаклар мәктәбендә укыдым. Юклык булса да күңелле иде. Беренче укытучым – Хәсәнова Шәмсинур апа булды. Наилә апа, Зәйтүнә апа, Фатыйма апа, Зәки абыйлар укытты. 1954 елда директор булып Хәдичә апа килде. Аның кызы Дарико апа да укытучы иде. Хәдичә апа һәрвакыт балаларның хәле белән кызыксынып торды. Мин моны бик яхшы хәтерлим».*



***НУРГАЛИЕВА ГӨЛБӘРИЯ ГАЛИ КЫЗЫ***

*«1935 елның 9 сентябрендә Казаклар авылында туганмын. 1940 елда әтием Ленинградка төзелеш эшләре буенча эшкә киткән. 1941 елның 22 июнендә сугыш башланганда ул шунда булган. Эштән кайтканда, шәһәрне бомбага тоталар. Аның белән безнең авылдан Хәсәнов Рәхим абый да булган. Алар шунда аерылганнар. «Мин Галине бүтән күрмәдем», – дип сөйли иде Рәхим абый. Әтидән бары бер генә: «Сугышка кердек», – дигән хаты килә. Үлгән дигән хәбәре дә килмәде, хәбәрсез югалган. Әти авылдан сугышка китмәгәнгә, безгә пособие дә бирмәделәр. Ниндидер сәбәпләр аркасында «Хәтер» китабына да кертелмәгән. Әни дүрт баланы бик авырлык белән генә үстерде. Ат кузгалагы, ашарга яраклы үләннәр җыйдык. Яз җитүгә, җир ачылыр-ачылмас, басуга черек бәрәңге җыярга чыга идек. Ач булсак да, күңел ача белә идек. Мөмкинлек булганда «Чүрәкәй», «Бабай», «Трак-трак» уеннары уйнадык.*

*Бер вакыйганы яхшы хәтерлим: 1944 елда бакчада бәрәңге алганда, авыл өстеннән җиде самолёт очып үтте. Бомба ташлыйлар дип, бөтен кеше өйләренә кереп качты. Шул вакытта бик курыктык.*

*1945 елның 9 мае бик матур кояшлы көн иде. Бер хатын урам буйлап: «Без җиңгәнбез, без җиңгәнбез», – дип кычкырып үтте. Без тәрәзәдән карап калдык. Әти кайта дип бик көттек, ләкин кайтмады. Үле хәбәре килмәгәч, әни соңгы сулышына кадәр көтте. «Менә кайтыр, менә кайтыр», – дип, тәрәзәдән күзен алмады.*

*1951 елда 7 нче сыйныфны тәмамладым, шуннан колхозда эшләдем», – дип сөйләде Гөлбәрия Гали кызы Нургалиева.*

*Ә Нәкыйбә Мәүли кызы Шәрипова: «Мин Өлләә авылында укыдым. Мәктәпкә барганда берәр утын агачы кыстырып бара идек. Укудан кайткач, арба-чана тартып, урманга китәбез. Көн саен диярлек авылга кара мөһерле кәгазь килә. Күз яше, кайгы, хәсрәт... Шулай булса да балалар балалар инде, эшкә ярамаган кечерәкләр көне буе күлмәк-штансыз урамда уйныйлар иде. Ул вакытта урам ямь-яшел чирәм, пыяла ватыгы да, тимер-томыр да аунап ятмый иде. Әти сугыштан яраланып, тугыз ай хезмәт итеп кайтты. Сугыш вакытында Үтәмеш басуыннан бәрәңге җыярга бара идек. Аяктагы чабата юешләнә, алыштырырга икенче аяк киеме дә юк. Утны күрсәтмәс өчен, тәрәзәләрне әйбер белән каплаталар иде. Тоз, шырпы юк. Әмма барыбер яныбызда әти булгач, җиңелрәк булды», – дип истәлекләре белән бүлешә.*

*Сугыш балалары үз вакытларын дөрес бүлә белгәннәр: укырга, эшләргә, ярдәм итәргә, күңел ачарга да өлгергәннәр. Күпме еллар узса да, халык хәтерендә ул еллар. Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр, һәм халкыбызның кылган батырлыклары һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән искә алыныр.*

*Бөек Ватан сугышының дәһшәте – көл булган шәһәр, авыллар өстендә, яу кырыннан кайтмый калган ир-егетләр, әти-бабайлар кабернлегендә. Аның сары сагышы – әтисезләр йөзендә. Алар сугыш дигән ачы хәсрәтнең фаҗигасен туганнан ук тоеп, үз күзләре белән күреп, ачлык-ялангачлыкның ни икәнен татып үскән. Алар – утлы елларда туган балалар. Шуңа күрә сабыр, нык алар.*

*Без, яшьләр, сугыш афәтен, аның бөтен фаҗигасен язучыларыбыз, шагыйрьләребез язган әсәрләр аша, бабаларыбыз сөйләгәнне тыңлап кына күз алдына китерәбез. Абый-апалар сөйләгәндә, А. Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар» повесте геройлары күз алдымнан үтте. Яшәү*

җиңел булмаса да, тырышканнар. Кул чаналары тартып, ачлы-туклы килеш, март аеның карлы-буранында 50-60 чакрым юлны үтеп, ашлык алырга барырга туры килгән бит безнең әби-бабайларга.

Фатыйма Шакир кызы Сафина истәлекләреннән: «Мин МТС та укып кайтып, көзге чәчүдә трактор белән эшләүдә катнаштым. Ул вакытта тракторлар кыш көне йөри алмый. Шуңа күрә окоп казуда да катнашырга туры килде. Язларын Биектаудан чана белән симәнә ташуда һәм башка эшләрдә эшләдек».

Мин шуны аңладым: кеше яшәү өчен көрәшкән. Шуңа да теләгем бер: сугышлар булмасын, җирдә һәрвакыт тынычлык хөкем итсен иде. Кешелек дөньясы, сугышлардан ачы сабак алып, җир йөзендә мәңге тынычлык, бәхет өчен көрәшсен иде!

Эльвина Сабитова,
Казаклар төп гомуми белем мәктәбенең 8 нче сыйныф укучысы



Алсу Салахиева, ученица 5 класса Высокогорской средней школы №3

# СУГЫШ ЕЛЛАРЫ ХАТИРӘЛӘРЕ БИТАРАФ КАЛДЫРЫРЛЫК ТҮГЕЛ

*Сугыш елларның ачысын да, төчесен дә күреп үскән балалар, бу афәтле елларны искә алганда, күзләреннән яшьләр тәгәрәп төшә. Галимә Җамали кызы Баһавиева – шул балаларның берсе. Аның белән хатирә иленә чумдык.*

*Әтиләре сугышка киткәндә Галимә апага яшь ярым була. Гаиләдә ике игезәк кыз һәм 4 яшьлек малай – абыйлары була. Әниләре сөйләве буенча, әтиләре балаларын башларыннан сыйпап чыгып китә. Бу әти кешенең соңгы тапкыр назлавы була.*



***ГАЛИМӘ ҖАМАЛИ КЫЗЫ БАҺАВИЕВА***

*Галимә апаның әтисен 1941 елда ук алып киткәннәр. «Безнең дәү әниебез дә бар иде, без әнигә 4 җәфа калдык», – дип искә ала Галимә апа. Галимә апаның әнисе – Саимә апа бик тырыш хатын булган. Үзләренә дә ашарга әйбер булмаган авыр вакытта, сыер, сарык, тавык асраган. «Балаларым сепарат сөтен булса да ашап калырлар», – дип, атланмай ясап тапшыра торган булган. Ул вакытта хөкүмәткә, тавык тотсаң – йомырка, сарык тотсаң – йон тапшырырга кирәк булган. Ә фронтка исә оекбаш белән бияләй бәйләп илтә торган булганнар. Галимә апалар, инде үсә төшкәч, әниләренә булыша башлаганнар.*

*Басуда бакча казыганнар, ухалла арбасы белән тирес ташыганнар, шуннан әзме-күпме бәрәңге алганнар. Урманнан ботаклар алып кайтып, өйләрен җылытканнар. Мәктәпкә укырга, өй эшләрен әзерләргә вакытлары да булмаган.*

*«Ашауга килгәндә, кычыткан ашлары, бәрәңге яфрагы, җиләк- җимеш, кузгалак җыеп ашый, күкәрин бәрәңгесеннән он игеп, күмәч пешерә идек. Ул булса ярый әле, тамак тук була иде. Председатель анысын да җыйдырмый иде. Җәйгә чыккач, печән богылы астыннан тәтем чыга иде. Аның бик тәмле бәрәңгесе бар иде. Шунда бөтен авыл балалары җыелып ашый идек. Шулар коткарып калган инде безне», – дип искә ала Галимә апа.*

*Әниләре өйне җылытырга урманнан утын ташый торган булган. Сорт участогында орлыкларны аралаучы булып эшләгән. Үлчәп алып, эшен өйгә дә алып кайта торган булган, бергәләп утырып чистартканнар.*

*Укуга килгәндә, балалар бик күп булган. Галимә апа яшендәгеләр генә дә 34-35 балалык А,Б,В,Г,Д,Е,Ж сыйныфлары булган. Мәктәпләрдә бик салкын булган, аякка чабата кигәннәр, китапларны салып йөрергә сумкалар, язарга дәфтәрләре дә булмаган. Шуңа карамастан, укытучылар бик яхшы, акыллы булганнар. Укучылар пионер булуны бик нык көтеп алганнар.*



*Сугыш беткәндә Галимә апага 7 яшь була. «Ул елны яз иртә килде, шатлыклы хәбәрне ишеткәч, без, бөтен балалар, яланаяк йөгереп йөргәнне хәтерлим», – ди Галимә апа. Әниләренең акчасы булса, язга чыкканда аларга башмак алып бирә торган булган. Игезәк кызлар моңа бик шатланганнар. Сугыштан кайткан кешеләрне бик шатланып каршы алганнар. Туганнары сугыштан кайткан йортта шатлык булган, ә кемдер, Галимә апалар кебек, гомер буе әтиләрен көткәннәр.*

*Сугыштан соңгы еллар, Галимә апа сөйләве буенча, тагын да авыр булган. Әниләре таякка эшләгән, шуның өстенә заемга ит җыя торган булганнар. Әтиләре яки абыйлары сугыштан кайткан гаиләләрдә алай ук азапланмаганнар, чөнки аларның йортларында ярдәм булган. Нинди генә эшкә тотынсалар да, ир көче ир көче инде. Ә Галимә апалар гомер буе азапланып яшәгәннәр. Ачлы-туклы килеш әниләре кая гына бармаган, ниләр генә күрмәгән. Галимә апа үзе дә әнисенең ул караңгы тормышта сынып-сыгылып калмавына әле бүген дә соклана.*

*«Әтиебез яшьли үлеп калса да, безне шушы көнгә кадәр, искә дә алмыйлар. Дәүләт тарафыннан берничди ярдәм дә күргәнебез юк. Мин бик нык әрним, бу еллар йөрәккә мәңге уелып калганнар», – ди Галимә апа.*

*Яшь буынга Галимә апаның теләр теләге шул: «Кадерле балаларым, оныкларым, без күргәнне күрә күрмәсеннәр. Тыныч, матур яшәсеннәр, сугыш дигән афәтне белми, бәхетле булсыннар. Иң мөһиме – тырышып укысыннар! Укыгын кеше генә бу тормышта үзен таба ала. Бүгенге көндә моның өчен бар мөмкинлекләр дә бар».*

*Фирүзә Сәләхова,*
*Зур Битаман мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*

# МАТУР, БӘХЕТЛЕ БАЛАЧАК УРЫНЫНА НӘРСӘ КҮРГӘННӘР СОҢ АЛАР?

*Без, яшь буын, бүгенге тыныч тормышыбыз өчен сугыш ветераннарына, тыл хезмәтчәннәренә, сугыш чоры балаларына мең-мең рәхмәтле, бурычлы. Кызганыч, дөнья мәшәкатьләре белән бу кайвакыт истән чыгып китә.*

*Сугыш чоры балалары... Матур, бәхетле балачак урынына нәрсә күргәннәр соң алар?*

*Сугыш чоры баласы – 1933 елның 7 гыйнварында Биектау районының Зур Битаман авылында туып үскән Рәшидә Сибгать кызы Гыйбадуллина белән булган әңгәмәне сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәм.*



***РӘШИДӘ СИБГАТЬ КЫЗЫ ГЫЙБАДУЛЛИНА***

*«Әтиемнең сугышка киткән көне исемдә. Ул колхоз наряды белән урман кисеп йөри иде. Эштән кайтып, капка төбендә ауган койманы рәтләп ятканда, авылыбызның Җәләлетдин дигән кешесе кәгазь тотып килде дә: «Сибгать, сине сугышка чакыралар», – диде.*

*Әти эшләгән урыныннан бүкәнгә балтасын кадап куйды да:*

*– Ярар, мин генә кала алмам инде, – дип, өйгә кереп китте. Мин дә шунда әтигә булышып йөри идем.*

*Без 4 бала: миңа – 8 яшь, Рәисәгә – 6 яшь, Суфиягә – 3 яшь Исмәгыйльгә – 3 ай. Бу хәбәрне ишетеп, бик еладык.*

*– Еламагыз, без ул немецларны гына җиңмәскә... – дип, әти безне тынычландырды. Шул көнне әни мунчага якты, әтинең капчыгына киемнәрен һәм ипи пешереп тыкты.*

*Икенче көнне әни әтине озатырга районга китте. 3 айлык Исмәгыйль энемне, әни миңа, күрше Әминә апага алып кереп, имезергә кушып калдырды. Без – 4 бала әтине авыл башына кадәр озаттык. Әтине озатып кайткач, энем елый башлады. Әминә апага кереп, 3 айлык Исмәгыйльне имездереп алып чыктым. Әни кич белән кайтты. Шулай, әтиебез киткәндә без әниебезгә 4 бала булып калдык. «Иң олысы мин идем идем», – дип искә ала Рәшидә апа, әтисе белән аерылышкан ачы мизгелләрне.*

*Тормышлары әниләре җилкәләренә калган көннән башлап, Рәшидә апага дә кинәт үсәргә туры килә. Урак вакыты җиткәч, бар халык уракка төшә.*

*Яшь балалары булган хатыннарны якынрак басуга җибәргәннәр. Рәшидә апа шул басуга сеңелләрен ияртеп, энекәшен имезергә алып бара торган була.*

*«Бер вакытны әни янына барганда, арба ватылып, энем күпердән төшеп китте. Мин бик нык курыктым. Арба ватылгач, баланы күтәреп алып барырга туры килде. Әни баланы имезгәч, бергәләп кайтып киттек», – дип искә ала ул авыр вакытларны Рәшидә апа.*

*Рәшидә апалар ачлыктан тилмермәгәннәр. Бакчалары, азмы-күпме бәрәңгеләре булган. 25 сутыйлы бәрәңге бакчасындагы бар эшне кул белән башкарганнар: казыганнар, тырмалаганнар, утыртканнар, алганнар. Көне буе урак урган кешегә, колхоз 200 грамм икмәк белән түләгән. Ул икмәкне он итеп, шуңа бәрәңге игеп, ипи пешерә торган булганнар. Шуның өстенә сыерлары булган. Әтиләре киткәндә: «Сыерыңны бетермә, Факия. Ни генә булса да асрарга тырыш», – дип киткән. «Асраган хайваныңның бәрәкәтен күрсәң, бер хәл», – дип искә ала Рәшидә апа. Заем җыйдырып тилмерттеләр: йомыркасын, сөтен, барысын да тапшырырга кирәк булды. Тавык булмаса да, йомырка тапшырырга тиеш идек».*

*Ул елларда кышлар бик салкын килгән. Өйгә икешәр тапкыр якканнар, тәрәзәләргә саламнар кыстырганнар, ишекләргә икешәр кат юрганнар кора торган булганнар. Бик азапланганнар. Әниләре балаларны мич башына меңгезеп йоклаткан. Үсә төшкәч, әниләре Рәшидә апаларны, капчык тоттырып, урманга чыбык-чабыклар җыярга җибәрә торган булган. Ул чыбык белән казан астына якканнар. Ул*



*ӘТИСЕ СИБГАТЬ ГЫЙБАДУЛЛА УЛЫ ГЫЙБАДУЛЛИН*

*вакытта керосинкалар булмаган, ашарга казан астына ягып пешергәннәр. Кышка кергәндә әниләре утынны сатып алган. Кайсы елны урман каравылчыларыннан «билет» белән ала торган булган. Утын мәсьәләсе сугыш беткәч тә дәвам иткән. Сугыштан кайткан ир-атлар үгез җигеп, утынны алып кайтып биргәннәр.*

*12-13 яше тулган балаларны, кыр эше беткәч, кружкалар тоттырып, басуга, төшеп калган башакларны, борчакларны җыярга чыгарганнар. Өлкәннәр кружкадагы бөртекләрне, артларыннан капчык белән җыеп йөргәннәр. Ә кичләрен әниләре фронтка оекбашлар, бияләйләр бәйләгән.*

*Рәшидә апалар 1 нче сыйныфка 30 бала кергәннәр. Бу хәл сугыш башланган елны була. Рәшидә апа яхшы укый, матур яза, ел саен күчеп бара. 7 нче сыйныфны бетергәндә, 30 баланың бары 3-4 генә кала, калган укучылар күчми калганнар. Нинди китаплар белән укыганын төгәл генә әйтә алмаса да, 3-4 кешегә бер китап икәнлеген ачык хәтерли Рәшидә апа. Берсеннән-берсе алып торып укыганнар. Олырак сыйныфларны бетереп чыгып киткәннәрдән сатып алганнар. Өйгә кайткач, дәрес хәзерләргә керосин булмавы сәбәпле, сукыр лампа яндырганнар. Якты вакытта бакча чүбе утыйсы булган.*

*Пионерга кергән вакытын Рәшида апа ачык хәтерли. Аны дружина вожатые итеп сайлыйлар. Балалар бергәләп концертлар куеп йөргәннәр, җырлаганнар, биегәннәр, Рәшидә апа шигырьләр сөйләргә яраткан.*

*«Нәрсә бар – шуны кидек. Әни ак бәз сатып алып, төрле буяуга манып күлмәкләр, итәкләр тегеп кидерде. Әтинең пәлтә тектере-*



## ӘНИСЕ ФАКИЯ МӨҺӘМӘДИ КЫЗЫ ГЫЙБАДУЛЛИНА

*гә дип алып калдырган тукымасыннан апага һәм сеңлемә бишмәт тегеп киерткәнен хәтерлим. Аякта – чабата, аңа күтәрмәләр куеп кисәк, язга чыккач башмакка күчә идек. Ул чабата белән аяклар үзәккә үтәрлек итеп туңа иде. Бераз гына җылы булмасмы дип, чүпрәккә мамык тутырып, аны сырып, чабата эченә салып кидек. Соңыннан, шәһәрдә яшәүче туганнарым үзләреннән калган киез итекләрне кайтардылар. Без аларны ямап, шатлана-шатлана киеп йөрдек», – дип сөйли ветеран апабыз.*

*Бәлки сугыш хәсрәте тәрәзәгә какмаган булса, Рәшидә апа укуын дәвам итеп, югары белем алган булыр иде. Сугыш бик күпләрнең хыялларын җимергән кебек үк, Рәшидә апаны да читләтеп үтмәгән. Ул әнисенең ярдәмчесе, эне-сеңелләренең төп таянычына әйләнә. 7 классны укып бетерүгә Рәшидә апаны ат карарга фермага куялар һәм ул җиде ел колхозда ат карый. Җәй көне атларны басуга эшкә алып чыгып киткәндә, Рәшидә апа атлар артыннан су күтәреп барып, аларны барлап кайта торган була. Бу эше өчен аңа бригадир көненә бер телем ипи бирә. Ул ипине Рәшидә апа энесенә алып кайта.*

*Рәшидә апаның әтисе Сибгать абый укымаган, шуңа да сугыштан бары тик 3 хаты гына килеп өлгерә. Бер хатында сугышның бик озак барачагын, балаларны ничек тә ачлыктан саклап калырга кушып язса, икенче хатында үзенең солдатларга ашарга пешерүче булып хезмәт итүе турында яза. Бу вакытта ул Смоленскта була. Өченче хатында исә бик каты яраланганлыгы хакында, озакламый кайтуы турында хәбәр итә. Ләкин госпитальне немецлар бомбага тоталар.*



*Фотода Рәшидә, 1933 елгы (сулда утыра), Рәисә, 1935 елгы (сулда баскан); Суфия, 1938 елгы (уңда утыра), Исмәгыйль, 1941 елгы (уңнан баскан)*

*Озак та үтми: «Смоленский өлкәсендә ирегез үлде», – дигән кара кәгазь килеп төшә. Әниләре бу хәбәрне бик авыр кичерә. «Бер көнне әни басудан авырып кайтты.15 көн әнине идәнгә салып, караулап чыктык. Аны селкетергә кушмадылар. Бары песоклы чәй генә эчердек. Бу авыр хәбәр белән әни шулай көрәште. 4 бала хакына ул исән калды, терелде», – дип искә ала Рәшидә апа.*

*«Сугыш бетте» дигән шатлыклы хәбәрне Рәшидә апа мәктәптә ишетә. Авыл советы каршысына укучыларны җыеп, демонстрация оештыралар. Бөтен авыл халкы шатланышып, елашып, көлешеп бәйрәм итә.*

*«Соңыннан күрше йортларга әтиләре, абыйлары кайта башлады. Иң беренче булып безнең урамга Зөбәер абый кайтты. Энем Исмәгыйль аның малае Рафис белән бик якын дус иде. Рафис әтисенә «әти» ди. Энем Исмәгыйль дә Зөбәер абыйга «әти» дип эндәшә башлый. Шуннан әни: «Улым, синең әтиең түгел ул, алай дияргә ярамый, – дигәч, энекәшем: «Минем дә бик нык «әти» диясе килә, – дип бик озак елады», – дип исенә ала Рәшидә апа.*

*Сугышка Сибгать абый үзенең абыйсы Габдулла, энесе белән бергә китә. Абыйсы Габдулла Гыйбадулла улы Гыйбадуллин сугыш кырында хәбәрсез югала. Әтиләренең энекәше кайта. Ул авылга төнлә кайта. Капка каккач, аны дезертир дип белеп, Рәшидә апаның әнисе – Факия апа аны кертми. Ул төнне бу солдат күршеләрдә үткәргән. Соңыннан ул абыйлары Казанга китеп урнаша.*

*Сугыш беткәч тә әтиләре фронттан кайткан кешеләрнең тормышлары азмы-күпме җайлана башлый. Рәшидә апаларга сугыштан соң да бик авыр булган. Бөтен авыр эш хатын-кыз һәм балалар җилкәсенә калган. Шулай да 72 сум пенсия акчасы бик ярдәм итә.*

*Нинди генә авырлыклар кичермәсен, кеше матурлыкка, тынычлыкка, бәйрәмгә омтылган. Сугыш беткәч тә, авыл халкы елгада боз кузгалганын бәйрәм итергә җыелган: чаналар шуып, шатланышып-куанышып, бөтен авыл бердәм гаилә булып, язны каршылаган.*

*Сугыш вакытындагы хезмәтләре өчен, дәүләт Рәшидә апаны «Хезмәт ветераны» медале белән бүләкли. Бүгенге тормышыннан Рәшидә апа бик канәгать.*

*Энесе Исмәгыйль аңа: «Апа, син мине ачлыктан алып калдың», – дип, очрашкан саен, күз яшьләре аша, рәхмәтен җиткерә.*

*Бүгенге көндә Рәшидә апага 83 яшь. Ул кызы тәрбиясендә матур гына гомер кичерә.*

*«Кадерле балаларым, исән-сау булыгыз, тормышның кадерен белеп яшәгез. Сез бик бәхетле, матур киенәсез, тәмле ашыйсыз. Исән-сау гына яшәгез. Дөнья тыныч булсын! Без күргәнне сезгә күрергә язмасын», – дигән теләктә кала.*

*Фирүзә Сәләхова,*
*Зур Битаман мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*

# ДӘҮ ӘНИЕБЕЗ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАБЫЗ



***ШӘМСЕРУЙ ШАКИР КЫЗЫ ХӘКИМҖАНОВА (БИКМӨХӘММӘТОВА)***

*Безнең дәү әниебез – Шәмсеруй Шакир кызы Хәкимҗанова (Бикмөхәммәтова) 1931 елның 5 апрелендә, хәзерге Биектау районы Айбаш авылында, Шакир һәм Мәйсәрә исемле кешеләр гаиләсендә туган.*

*Әтисе сугышка кадәр бай кешеләргә барып хезмәт иткән, сугыштан соң колхозчы булган, оста итеп мич чыгарган. Әнисе дә колхозда эшләгән, башкалар белән бунты (эскерт) өеп йөргән.*

*Гаиләдә алар өч бала булган: энесе – Сәләхетдин, апасы – Зөлхәбирә исемле. Әтисе сугышта киткән. Әмма көннәрнең берсендә, йөрәге сау булмау сәбәпле, аны сугыштан кайтаралар. Аннан соң әнисе, өч баланы калдырып, окоп казырга Лаеш ягына киткән. Кайткач, ире урынына Гәргә урман кисәргә төшеп китә, бер айдан соң гына кайта. «Әтиебез бер, ана башка булган Гыйният абыем да сугышка китте, исән-сау әйләнеп кенә кайта алмады», – ди дәү әнием.*

*Әти-әни назында гына яшәү туры килмәгән бу чор балаларына. Дәү әнием бу турыда болай дип искә ала: «2 класс кына укый алдым... Чәчү чәчтем, укырга мөмкинлек булмады. Машина ашлык сукканда, ат куып йөрдем, атлар карадым. Сугыш вакыты бик*

*авыр булды шул, Казанга барып ипи алып булмый... Чират торасың, ашарга юк, кузгалак, бәрәңге яфрагы, черек бәрәңге ашадык...»*

*19 яшендә күрше Суыксу авылы егете Галимҗан (минем дәү әтием) белән тормыш корып җибәрәләр. Дәү әни колхозда фермада сыер сава. Уңган, булган дәү әнием авыл советында дүрт ел депутат булып тора. Хезмәте өчен бик күп Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Алар эшендә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен, сыер савучылар арасында гел алдынгы урынны алганы һәм терлекчелектә намус белән эшләгәне өчен бирелә.*

*Дәү әти белән дәү әни җиде бала тәрбияләп үстергәннәр. Быел аларның бергә гомер итүләренә 60 ел булыр иде, дәү әтием кинәт кенә авырып үлеп китте. Бүгенге көндә без дәү әни белән яшибез. Аның егерме ике оныгы һәм оныкчыгы бар. Әле дә һәммәбезне тәмле өчпочмаклары, сөзмәләре белән сыйлый дәү әнием. Без аны бик яратабыз. Саулыгы белән безнең янәшәдә яшәвен һәм озын гомер кичерүен телибез.*

*Нияз һәм Азат Хәкимҗановлар,*
*Суыксу мәктәбе укучылары*



*Рашида Тахирова, ученица 7 класса Высокогорской средней школы №3*

# МОЯ БАБУШКА – ДОЧЬ СОЛДАТА




*ДАУТОВА ФИРДИНА ХАФИЗОВНА*

*Моя бабушка – Даутова Фирдина Хафизовна, родилась 20 марта 1942 года в деревне Качелино Арского района ТАССР. Когда её отец, Хафизов Хаким Хафизович, ушёл на фронт, в семье осталось пятеро детей. Уходя, он наказал своей жене беречь детей, сказал, что война кончится победой, и что он обязательно вернётся домой живым и здоровым. Его в деревне очень уважали.*

*Моя прабабушка работала в колхозе: на ферме и на элеваторе, не зная отдыха. Было голодно, детей кормить нечем, всё отдавали фронту. Записывались на заём, платили молоком, мясом, шерстью, яйцами. Питались в основном травой. А когда в поле собирали гнилую картошку, надо было скрываться, так как бригадир ругал и гнал с поля.*

*Топить дом в зимнее время тоже было нечем. Поэтому они в любую погоду ходили в лес за сухими ветками. И то вечерами, ведь в лес тоже не пускали. Дети собирали коровьи кизяки, сушили на солнце и ими топили печь.*

*Рассказы бабушки Фирдины о своём детстве, военном и послевоенном времени меня всегда волнуют. Сколько же горя они испытали! Она не знала слово «папа», потому что родилась после гибели своего отца.*

*Мой прадед – Хафизов Хаким Хафизович, 1906 года рождения, был призван на фронт в 1941 году. Служил в 54 отдельном сапёрном батальоне 5 стрелковой дивизии, красноармеец. Погиб 4 декабря 1941 года около деревни Юрьевск (Калининский район, Каблуково), защищая Москву. В 1975 году сёстры бабушки ездили в город Калинино. Наши бойцы были перезахоронены в деревне Каблуково. Здесь, в 25 километрах от Москвы, погибло 1500 бойцов Красной Армии.*

*В деревне Качелино Арского района, где родился и жил мой прадед, Хафизов Хаким Хафизович, ежегодно проводится торжественный митинг, посвященный героям-землякам, читаются молитвы.*

*Спасибо всем жителям деревни Качелино, что не забывают о погибших земляках. Всем людям желаю мира, здоровья и благополучия.*

*Руфина Фаргатовна Шарипова,*
*воспитатель детского сада «Тургай»*




*Кира Надиенко, ученица Бирюлинской средней школы. 8 лет*

# ЮНЫЕ ГЕРОИ ВЕЛИКОЙ ВОЙНЫ



*МАНСУР ЮНУСОВИЧ БИЛАЛОВ*

*Мансур Юнусович Билалов родился 10 января 1930 года в деревне Губурчак Арского района Татарской АССР, в семье колхозника. Его родители в 1930 году вступили в колхоз. Отец с 1930 по 1937 годы был председателем колхоза.*

*Мансур Юнусович рано остался сиротой. Мать, после долгой болезни, умерла в 1939 году. Отец ушёл на фронт в 1941 году. А в феврале 1942 года пропал без вести.*

*Так Мансур Юнусович вспоминает начало войны: «Ровно в 12 часов заговорил репродуктор. Первыми словами из репродуктора прозвучали слова «Внимание, говорит Москва». По радио началась передача с заявлением Советского правительства. Выступил народный комиссар иностранных дел – В.М. Молотов.*

*В заявление было сказано: «Сегодня в 4 часа утра без предьявления каких-либо претензий к Советскому союзу, без обьявления войны, германские войска напали на нашу страну, атаковали наши границы, во многих местах подвергли бомбёжке со своих самолётов наши города…» Заявление Советского правительства завершилось словами: «Наше дело правое, враг будет разбит. Победа будет за нами!» После закрытия митинга народ со слезами на глазах медлен-*

*но группами разошёлся по домам… Многие мужчины призывного возраста в тот же день стали готовить одежду, продукты и стали ждать повестку из райвоенкомата…*

*Наш Казанский гость – Сулейман абый в тот же день уехал домой». Очень сильно переживал отец Мансура Юнусовича – Юнус Билалович Билалов. Он один воспитывал пятерых детей. Война значительно осложнила жизнь семьи. Отец рано утром уходил из дома и возврашался очень поздно. Его указания, что делать в его отсутствие дома, получали самая старшая – Тойфа апа (ей было 13 лет) и Мансур (ему было 11 лет). Перед отцом стоял вопрос, где оставить детей? В Арском лесопункте или вывести их в родную деревню Губурчак Арского района ТАССР.*

*В связи с началом войны Лесопункт Шеморданского лесхоза был переведён на станцию Корса. Во время войны на этой станции пилили лес и дровами заправляли паровозы. В стране не хватало угля для заправки топливом паровозов, даже для военных грузов.*

*Их отец выбрал правильное решение. Он погрузил всё их имущество в две конные тележки. В переднюю тележку посадил своих пятерых детей. В заднюю погрузил мебель, двух коз, которые должны были снабжать их своим молоком. Таким образом, война заставила их вернуться обратно в свою деревню. Отец до призыва в армию ходил на работу, на станцию Корса, где продолжал выполнять обязанности завхоза в лесопункте. А дети будущего фронтовика стали работать в колхозе.*

*Мансур абый вспоминает: «В труде и заботах ушло лето. В конце августа 1941 года из Арского райвоенкомата более 10 человек получили повестку для отправки на фронт. Среди них оказался и их отец Билалов Юнус Билалович, 1903 года рождения. Из каждой семьи сопровождать до Арского военкомата разрешалось по одному человеку. Из их семьи сопровождать должен был Мансур. Провожать уходящих на фронт мужчин собралась вся деревня. Жёны и дети плакали, а уходяшие на фронт мужчины старались их успокоить, давали советы женщинам об управлении домашним хозяйством. Для многих жён и детей эти проводы были последней встречей с родными.*

*Наконец лошади тронулись, взяли курс в деревню Масру, Купербаш и в райцентр Арск. Пока ехали, небо покрылось тучами, в Арске стал моросить дождь. Подьехали к зданию военкомата, все призывники ушли в помещение, а провожающие с нетерпением ждали их возвращения.*

*Одним из последних из военкомата вышел их отец, подошёл к их телеге, крепко обнял и поцеловал сына, говоря при этом: «Ты в семье у нас старший мужчина, помогай сестре, продолжай учёбу, у тебя это хорошо получается. Нас, видимо, сегодня на поезде отправят в Марийские леса». Ещё раз крепко обняв сына, ласково похлопав по спине сказал: «Как приедем, напишу письмо».*

*Отец сдержал свое обешание: через неделю дети получили первое письмо о том, что они живут в лесах, недалеко от Казани, строят землянки, окопы и другие сооружения, и учатся воевать с немцами. В одну тёмную ночь на грузовой машине их отец приехал домой. Его сопровождал офицер его части. Они очень торопились. Он разбудил всех и сказал, что он приехал за столярными инструментами. У доме их было много. Все столярные работы отец выполнял сам. Эти инструменты ему пригодились в Марийских лесах при строительстве военных сооружений.*

*В январе 1942 года в воинскую часть, где служил их отец, из Марийских лесов перебросили зашишать Москву. В своем последнем письме он написал, что они два раза были в бою. Он вышел из боя живым, готовился к следующему. Это было его последнее письмо. В той части, где служил их отец, много было фронтовиков из Арского района. Например, из деревни Культас. Некоторые из них вернулись живыми, но, к сожалению после войны они об отце никаких известий не передали. Много лет спустя кто-то из них рассказал, что подразделение, где служил Билалов Юнус Билалович, на поезде было переброшено на другой участок фронта. А когда поезд с солдатами проезжал по железнодорожному мосту, немецкие самолёты на мосту атаковали этот состав. Вагоны вместе с солдатами ушли на дно неизвестной реки в районе обороны Москвы.*

*На их запрос, сотрудники Арского райвоенкомата ответили: «Солдат Билалов Ю.Б. пропал без вести».*

*Мансур Юнусович получил профессию учителя. В нашей школе он долгие годы работал директором и учителем истории. Создал музей боевой славы. Он пользовался заслуженным авторитетом и уважением в селе и районе. В настоящее время его уже нет среди нас. Для написания этого текста мы воспользовались его дневником, который хранится в школьном музейном уголке…*

Ученики ДОО «Наследники Отечества»<br>Чепчуговской средней школы

# ПИСЬМО ПОБЕДЫ

С целью сохранения исторической памяти о Великой Победе Альдермышская средняя школа Высокогорского района РТ совместно с краеведческим музеем Салиха Сайдашева и районной ветеранской организацией присоединилась к Международной акции «Письмо Победы».

28-29 апреля 2021 года в краеведческом музее Салиха Сайдашева прошло торжественное мероприятие, посвящённое 76-й годовщине Великой Победы. Школьники и ветераны познакомились с выставкой «Во имя Победы», предоставленной национальным музеем РТ, посмотрели документальный фильм «Дети и война». После обсуждения просмотренного, решили написать письмо Победы, для вручения ветеранам своего села и района.

Позже письма были оформлены в солдатские треугольники и вручены ветеранам.




*Ученики Альдермышской средней школы Высокогорского района РТ*

ПИСЬМО УЧЕНИКА 9 КЛАССА БУЛАТА ВАЛИЕВА

*«Здравствуйте, уважаемый Ветеран!*

*Хочется сказать Вам спасибо за чистое и светлое небо над головой. За то, что я могу свободно бегать по зелёному полю, не бояться, не думать о том, что над головой в любой момент может пролететь пуля. За то я и мои друзья можем учиться и отдыхать. Можем мечтать о будущем.*

*Я горжусь, что живу стране Победителей. Я горжусь своими предками, дедушками и бабушками, которые воевали вместе с тобой плечом к плечу. Для всего нашего поколения Вы не просто Победитель, Вы – пример для подражания. Пример мужества, смелости, храбрости и отваги!*

*Вы подарили нам жизнь, и мы за это Вам безмерно благодарны. Страшно подумать, через какие испытания Вам пришлось пройти, сколько товарищей Вы потеряли в бою, и сколько из них умерло у Вас на руках. Страшно подумать, как Вам было тяжело, когда товарищей брали в плен. Может и сами попадали, но умело выбирались.*

*Мы счастливы, жить вместе с Вами на родной земле, ходить по одним и тем же дорогам и дышать одним воздухом, таким чистым, а главное – свободным.*

*Я желаю Вам крепкого здоровья, долгих лет жизни, внимания и заботы близких людей и радости в каждом дне. Мы всегда будем помнить Вас. Спасибо Вам за мирное небо над нашей большой страной.*

*Низкий Вам поклон!»*



# СУГЫШ

*Нинди тетрәндергеч сүз!*
*Үтеп керә күңел түренә.*
*Кемдер сөйләгәннәрдән,*
*Ә кемдер шаһиты булган*
*Сугыш җирендә.*
*Ул бит эзсез генә үтми:*
*Җимереклек, гарип-гораба,*
*Күпме сындырылган ачы язмыш,*
*Күпме толлар, ятим-ятимә!*
*Бу ачы хакыйкатьне булдырмаска,*
*Нәфесен тыю кирәк кешегә!*
*Гүзәллекне җирдә күрә бел син – кеше!*
*Күңел биреп башкар эшеңә!*

*Зәринә Җамалиева,*
*Биектау 3 нче урта гомуми*
*белем бирү мәктәбе укучысы*



*Артур Галиев, Биектау 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең*
*1 нче сыйныф укучысы*



*Амина Кадырова, ученица 7 класса Высокогорской средней школы №3*

# БАТЫРЛАРГА – ДАН

*Дәһшәтле сугышта солдатлар*
*Утларны, суларны кичкәннәр.*
*Чигенми дошманның утыннан*
*Адымлап җиңүгә барганнар.*

*Аларның күбесе әйләнеп*
*Кайтмады, табигать елады.*
*Табигать-анага кушылып,*
*Үзәкләр сызлады, сыкрады.*

*Күп вакыт узса да яралар,*
*Сызланып йөрәкне талкыйлар.*
*Батырларга куелган һәйкәлләр*
*Үлемсезлеккә дан җырлыйлар.*

*Гүзәл Госманова,*
*Биектау 3 нче урта гомуми белем бирү*
*мәктәбенең 6 нчы сыйныф укучысы*

# ДӘҮ ӘТИНЕҢ ӘТИСЕ – УЛ МИНЕМ ОЛЫ БАБАМ

*Егерме икенче июньдә,*
*Иртәнге сәгать дүрттә,*
*Герман сугыш башлаган*
*Тыныч Совет илендә.*

*Бөек Ватан сугышы*
*Күп афәтләр китергән.*
*Безнең ил кешеләре*
*Күп югалту кичергән.*

*Дәү әтинең әтисе*
*Солдатта хезмәт иткән.*
*Көзгә өйгә кайтам дип,*
*Кайту вакытын көткән.*

*Насыйп булмаган кайту,*
*Сугыш башлану белән.*
*Үзе теләп фронтка*
*Бабакаем да киткән.*

*Сугыш кыры куркыныч:*
*Атыш, шартлау, җимерү.*
*Шулар белән бергә әле*
*Әсирлеккә эләгү.*

*Нишләсен соң адәм башы?*
*Түзсә дә түзә икән!*
*Әҗәле җитмәсә кеше,*
*Барысын да уза икән.*

*Сугыш беткәч, өйгә кайту*
*Тиз генә насыйп булмый.*
*Шахтага эшкә җибәрәләр,*
*Ил кушкач – бармый булмый.*




*Динә Сәйфуллина, Биектау районының Суыксу мәктәбе укучысы*

*Шулай итеп, ул өенә*
*Ун елдан гына кайта.*
*Сугыштан соң тормыш авыр,*
*Тагын сынаулар арта.*

*Барысын җиңгән, тырыш*
*Дәү әтинең әтисе –*
*ул минем олы бабам.*
*Дүрт улы һәм бер кызы –*
*Аның бәхет җимеше.*

*Эльвира Сәләхова,*
*Биектау 3 нче урта гомуми*
*белем бирү мәктәбенең*
*6 нчы сыйныф укучысы*

# СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАСЫ

Дәү әниемнең әнисе –
Сугыш чоры баласы.
Сугыш башланганда аңа
Алты яшь була бары.

Әтиләре, барлык ирләр
Сугыш кырына китә.
Тылда калган кешеләргә
Авыр вакытлар җитә.

Ирләр эшләгән эшләрне
Хәзер хатын-кыз эшли.
Сугыш чоры балаларына
Әти назлары җитми.

Бар да җиңү өчен эшли,
Җиңү өчен тырыша.
Бердәм булгач, илем халкы
Максатына ирешә.

Югалтулар күп булса да,
Җиңү барыбер яхшы.
Рәхмәт сезгә Җиңү өчен,
Сугыш чоры баласы!

*Эльвира Сәләхова,*
*Биектау 3 нче урта гомуми*
*белем бирү мәктәбенең*
*6 нчы сыйныф укучысы*

# ҖЫР БУЛЫП ЯШИ КҮҢЕЛДӘ

Татар улы – милләт горурлыгы,
Каһарманы бөек Җиңүнең.
Муса Җәлил, аның батырлыгы –
Онытылмаслык җыры күңелнең.

Җанын биргән безнең халык өчен,
Сынмаган ул салкын зинданда.
Ышанган ул Җиңү киләсенә,
Җитәчәк дип матур язлар да.

Тоткынлыкта фашистларга каршы
Каләм төшми аның кулыннан.
Әсирләр дә аңа карап алга
Атлап бара аның юлыннан.

Кара болыт килгән...
Салкын җилләр әрнеп искәннәр...
Җәлилчеләр кайтмас инде кабат...
Авыр хәбәр илгә илткәннәр.

Көрәшкәннәр алар Ватан өчен,
Без аларны һәрчак зурлыйбыз.
Туган җиргә, илгә мәхәббәтне
Җырларыннан укып таныйбыз.

*Чулпан Хәбибуллина,*
*Биектау 3 нче урта гомуми*
*белем бирү мәктәбенең*
*5 нче сыйныф укучысы*



*Марсель Сафин, ученик 1 класса Высокогорской средней школы №3*



*Ясмина Шайхетдинова, ученица Высокогорской средней школы №3*



*Учащиеся Мульминской средней школы (кадетский класс) после встречи с ветеранами труда. Февраль 2020 года*




*Учащиеся Шуманской школы (отряд юнармейцев) после присвоения отряду имени героя Советского Союзы Яшина Григория Яковлевича. Май 2021 года*




*Юнармейцы Бирюлинской средней школы на выставке «Музей в чемодане». Апрель 2021 года*



*Председатель Республиканского Совета региональной общественной организации ветеранов (пенсионеров) РТ – Хабир Газизович Иштиряков, беседует со школьниками*



*Выставка учащихся Шапшинской средней школы «Инсталляции боевых действий». Апрель 2021 года*




*Учащиеся Чепчуговской средней школы героическим землякам...*

## СОДЕРЖАНИЕ / ЭЧТӘЛЕК

ПРЕДИСЛОВИЕ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .3
ГОВОРЯТ ДЕТИ ВОЕННОЙ ПОРЫ / СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАЛАРЫ СӨЙЛИ. . . . . . . . . . . . .5
Ананьева Мария Викторовна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Әхмәтҗанова Саимә Хидият кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .9
Әхмәтҗанов Сәлихҗан Закирҗан улы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .11
Багашева (Коровина) Анна Семёновна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .13
Березин Юрий Петрович . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .16
Березина Лидия Сергеевна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Белотелов Павел Григорьевич. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Бикмухамметова Фина Мухаметшиновна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .22
Васильева Сентябрина Яковлевна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .24
Гаврилова Анастасия Николаевна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .26
Газизов Әхәт Газиз улы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .28
Газизова Әминә Әхмәтгали кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .32
Гайфуллин Ахат Каримуллович. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Гайфуллина (Шайдуллина) Равиля Рахимжановна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Галяутдинова Дания Хисматовна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .39
Гарипова Флюра Фәиз кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .41
Гилязиев Равиль Галяутдинович. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Гилязиева Дарико Лотфиевна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .46
Горячева (Репина) Нина Андреевна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .49
Григорьев Василий Ефремович. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .51
Гуськова Екатерина Спиридоновна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .53
Дирзизов Ривгат Юсупович. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .55
Егорова (Бабанова) Мария Фёдоровна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .57
Журавлёва Мария Павловна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .59
Загидуллин Рафаэль Кашапович. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .61
Зарипов Абдулла Касыйм улы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .64
Зиганшин Нуряхмат Мубаракшинович . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .66
Зиганшина Рахиля Галиулловна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .68
Исхакова Саимә Гыйндулла кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .70
Кадыйрова Венера Абдулла кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .72
Козлова Мария. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .74
Кротова Александра Фёдоровна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .76
Крылов Юрий Артемьевич . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .78
Лапердина Анна Петровна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .81
Ларина (Жук) Александра Фёдоровна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .83
Максимова Валентина Ильинична. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .86
Маликов Әүзәх Малик улы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .89
Маликова Әминә Халик кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .92
Макаров Николай Михайлович . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .95
Минһаҗева Голбостан Насрулла кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Мифтахова Диляра Галимзяновна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Мубаракшин Ильберт Хабибрахманович . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Низамов Исмәгыйль Җамали улы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .106
Никитина Аннета Кузьминична. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Рахимзянов Салихзян Рахимзянович. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .110
Сабирҗанова Флёра Ахун кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .112
Садыйкова Әнзия Хәбир кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .115

Садикова (Гиззатова) Бибинур . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .117
Салмина Тамара Алексеевна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .119
Сафин Равил Габдрахманович. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .121
Сафина Маһирәҗәп Исмәгыйль кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .124
Сафина Султания Гарифулловна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .126
Сибгатов Хадиулла Гарифуллович . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Татаринова Таисия Львовна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Усова Ольга Михайловна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .133
Фаеков Вилдан Касыйм улы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Фаткуллина Асия Афзаловна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .138
Хаҗиәхмәтова Сания Мөхәммәди кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Хакимуллина Тарзима Ясавиевна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Ханова Гөлнур Әхмәтхан кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Хәкимҗанова Кәүсәрия Фатыйх кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .146
Хәсбиева Нурия Хидиятулла кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .148
Хөсәенова Кәүсәрия Шәрип кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Хуснуллина Дания Алимовна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Хуснуллин Хамза Алимович. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Хөснетдинова (Гыймадиева) Һәдия Шәйхи кызы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .158
Шавалиев Рифкат Абдуллович. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .161
Шамсиева Флюра Абдулловна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .163
Шумкова Вера Тихоновна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .165
Юнусова Асия Исмагиловна . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .167
Ягофарова Сания Давлетшевна. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .169
Якупов Шамиль Ильясович . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171

ГАЗЕТНЫЕ ВЫРЕЗКИ СВИДЕТЕЛЬСТВУЮТ/ СУГЫШ ЧОРЫ ГАЗЕТАЛАРЫ НИ СӨЙЛИ. 174
Не будьте ни одного дня без дела! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Замечательная инициатива школьников . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Трактор изучим на «отлично» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
У Коли Козырёва 180 трудодней. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Лучшие ученики премированы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .181
Яна уку елына отличнога . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Выполним свой долг перед Родиной . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .183

ФРОНТОВЫЕ ПИСЬМА / ФРОНТ ХАТЛАРЫ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .185
Письмо Мансура Абдулловича Абдуллина родителям . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .187
Шәвәли Баһави улы Баһавиевның тормыш иптәше Мәйсәрәгә язган хаты. . . . . . . . . . . . .190
Из письма Семёна Гавриловича Батрамеева жене Татьяне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .191
Письмо Петра Васильевича Васильева дочери Валентине. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .193
Малик Вәлиевның фронттан хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .194
Габделхак Мортазинның фронттан язган хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196
Фронтовое письмо Константина Степановича Панкова. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .202
Фронтовое письмо Дмитрия Борисовича Романова жене Катерине и детям. . . . . . . . . . . 204
Әхмәтҗан Сабировның әнисе Фәхернисага язган хатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205
Письма из блокадного Ленинграда Анны Дмитриевны Двоеглазовой . . . . . . . . . . . . . . .207
Письмо из блокадного Ленинграда А. Михайловой. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .212
Фотографии памятников и обелисков Высокогорского района РТ. . . . . . . . . . . . . . . . . . .214

СЛОВО ПРАВНУКАМ ПОБЕДИТЕЛЕЙ / ҖИҢҮЧЕЛӘР ОНЫКЧЫКЛАРЫНА СҮЗ БИРИК

Бабам. Ильяс Хәкимҗанов. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .221
Сугыш афәте кабатланмасын. Зөһрә Гайнуллина. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .222
Әтисез үтте балачагым. Сәвия Галиева. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 226
Я горжусь своими дедами. Артём Культяпов. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .229
Кешелек дөньясы тынычлык, бәхет өчен көрәшсен иде! Эльвина Сабитова. . . . . . . . . . .233
Сугыш еллары хатирәләре битараф калдырырлык түгел. Фирүзә Сәләхова. . . . . . . . . . . .240
Матур, бәхетле балачак урынына нәрсә күргәннәр соң алар? Фирүзә Сәләхова . . . . . . . .243
Дәү әниебез белән горурланабыз. Нияз һәм Азат Хәкимҗановлар . . . . . . . . . . . . . . . . .249
Моя бабушка – дочь солдата. Руфина Шарипова. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
Юные герои Великой войны. Ученики Чепчуговской средней школы. . . . . . . . . . . . . . . 253
Письмо Победы. Ученики Альдермышской средней школы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
Письмо ученика 9 класса Булата Валиева . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .257
Сугыш. Зәринә Җамалиева. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .258
Батырларга – дан. Гүзәл Госманова. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .259
Дәү әтинең әтисе – ул минем олы бабам. Эльвира Сәләхова. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .260
Сугыш чоры баласы. Эльвира Сәләхова. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .261
Җыр булып яши күңелдә. Чулпан Хәбибуллина. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .261
Фотографии учащихся Высокогорского района РТ с ветеранами. . . . . . . . . . . . . . . . . .263

Использованы рисунки Сагиды Ахметзяновой, Алсу Салахиевой, Киры Надиенко, Амины Кадыровой, Дины Сайфуллиной, Марселя Сафина, Ясмины Шайхетдиновой, Егора Гагулина, Ильяса Хакимзянова.

ИСПОЛЬЗОВАННЫЕ РЕСУРСЫ / КУЛЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР

1. Архивные материалы Совета ветеранов, краеведческого музея, музеев боевой и трудовой славы школ Высокогорского района РТ.
2. Фотографии из семейных архивов авторов воспоминаний, членов творческого коллектива.
3. Открытые интернет-ресурсы.
4. Книга «Хәтер. Память». Высокогорский район. Республика Татарстан, Казань. 1995 год.
5. Книга «Татарстан в годы Великой Отечественной войны (1941–1945 гг.). Казань. 2009 год.
6. Книга «Алар илгә җиңү алып кайтты. Они вернулись с Победой». Высокогорский район. Казань. 2009 год
7. Газетные вырезки. «Ленинский путь» (Орган ВКП)б) Высокогорского района и районного Совета народных депутатов ТАССР) за 1942–1943 гг.
8. Книга «Источник вдохновения», Клара Ахманова. Казань. 2018 год.
9. Творческие работы школьников Высокогорских школ №1 и №3, Бирюлинской, Шапшинской, Большебитаманской средних школ, Суксинской и Березкинской основных школ.

Подписано в печать 12.09.2023
Формат 70x100 1/16.
Тираж 500 экз. Заказ №86.

Отпечатано в АО «Областная типография «Печатный двор»
Адрес: 432049, г. Ульяновск, ул. Пушкарёва, 27